**Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы**

**Байлангар авыл җирлеге Башлыгы**

**карары**

**2020 елның 13 ноябре** **N19**

**«Кукмара муниципаль районы Байлангар авыл җирлеге Сазтамак авылында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын үткәрүне билгеләү турында»**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы һәм Кукмара муниципаль районы Байлангар авыл җирлеге Уставының 22 статьясы нигезендә

КАРАР БИРӘМ:

1. 2020 елның 26 ноябрендә 9 сәгать 00 минутка Кукмара муниципаль районы Байлангар авыл җирлеге Сазтамак авылында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының беренче этабын үткәрүне билгеләргә. Гражданнар җыенын Сазтамак авылы, Ленин урамы, 36а адресы буенча урнашкан Сазтамак башлангыч мәктәбе бинасында үткәрергә.

2. 2020 елның 26 ноябрендә 15 сәгать 00 минутка Кукмара муниципаль районы Байлангар авыл җирлеге Сазтамак авылында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының икенче этабын үткәрүне билгеләргә. Гражданнар җыенын Сазтамак авылы, Ленин урамы, 36а адресы буенча урнашкан Сазтамак башлангыч мәктәбе бинасында үткәрергә.

3. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга: «I төркем инвалидлар, укучылар һәм көндезге уку формасы буенча укучы студентлар (курсантлар), 18 яшькә кадәрге 3 һәм аннан күбрәк баласы булган әниләр, 80 яшьтәге һәм аннан өлкәнрәк затлардан кала, Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Байлангар авыл җирлеге Сазтамак авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр яшәүчедән 2021 елда үзара салымны 500 сум күләмендә кертергә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен юнәлтүгә сез ризамы:

- Сазтамак авылы зиратына материал сатып алу һәм коймалар урнаштыру; проект-смета документларын эшләү һәм техник күзәтчелекне тормышка ашыру;
- Сазтамак авылының Яр буе урамындагы юлларга вак таш җәю; проект-смета документларын эшләү һәм техник күзәтчелекне тормышка ашыру;
- Сазтамак авылының урам юл челтәрен карап тоту;
- Сазтамак авылында Бөек Ватан сугышында катнашучыларга куелган һәйкәлгә материаллар сатып алу һәм киртәләр урнаштыру; проект-смета документларын эшләү һәм техник күзәтчелекне тормышка ашыру;
- Сазтамак авылында Ленин урамына тышкы видеокүзәтү камералары сатып алу һәм урнаштыру (килешү буенча эшләр өчен түләү);

- Сазтамак авылында Ленин ур., 96 нчы йорт янындагы чишмәне төзекләндерү; проект-смета документларын эшләү һәм техник күзәтчелекне тормышка ашыру;

- Май урамы, 7 нче йорт янындагы чишмә территориясен төзекләндерү (бетонлаштыру, култыксалы/рәшәткәле баскыч урнаштыру; проект-смета документларын эшләү һәм техник күзәтчелекне тормышка ашыру);

- Май урамы, 7 нче йорт янындагы җәяүлеләр өчен култыксалы/рәшәткәле күперне төзекләндерү, проект-смета документларын эшләү һәм техник күзәтчелекне тормышка ашыру;

- Сазтамак авылындагы артезиан скважиналары өчен насослар сатып алу;

- Сазтамак авылы урамнарын яктырту өчен светодиод лампалар сатып алу.

«РИЗА» «КАРШЫ»

4. Гражданнар җыенын үткәрү өчен торак пунктта яшәүчеләрнең исемлеген территориаль билге буенча (урамнар буенча) бүләргә.

5. Гражданнар җыенын оештыручы итеп, Байлангар авыл Башкарма комитетын билгеләргә.

6. Әлеге карарны кабул ителгән көннән соң 5 көн эчендә мәгълүмат стендларында һәм Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында «Авыл җирлекләре» бүлегендә урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә.

7. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Авыл җирлеге Башлыгы: И. Х. Миңнегалиев